КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 3 март г.Казань № 167

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018/19 уку елында Татарстан Республикасында Россия Федерациясе халык хуҗалыгы оешмалары өчен идарә итүче кадрлар әзерләү буенча дәүләт планын тормышка ашыру чаралары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2019 ел, 13 февраль, 103 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018/2019 уку елларында Татарстан Республикасында Россия Федерациясе халык хуҗалыгы оешмалары өчен идарә итүче кадрлар әзерләү буенча дәүләт планын тормышка ашыру чаралары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2019 ел, 13 февраль, 103 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2018/19 уку елында» сүзләрен «2018/19 – 2024/25 уку елларында» сүзләренә алыштырырга;

преамбулда «2018/19 уку елында» сүзләрен «2018/19 – 2024/25 уку елларында» сүзләренә алыштырырга;

1 нче пунктта «2018/19 уку елында» сүзләрен «2018/19 – 2024/25 уку елларында» сүзләренә алыштырырга;

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына Татарстан Республикасындагы Россия Федерациясе халык хуҗалыгы оешмалары өчен идарә итүче кадрлар әзерләүнең дәүләт планын тормышка ашыру буенча чаралар исемлеген расларга».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин